Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының

Байлангар авыл җирлеге Башлыгы

карары

11 ноябрь, 2024 ел № 5

«Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Байлангар авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2024 елның 2 декабрендә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Байлангар авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә. Гражданнар җыенын Байлангар авылы, Совет урамы, 6 адресында урнашкан Байлангар авыл мәдәният йорты бинасында уздырырга.

2. 2024 елның 3 декабрендә 18 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Байлангар авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә. Гражданнар җыенын Байлангар авылы, Совет урамы, 6 адресында урнашкан Байлангар авыл мәдәният йорты бинасында уздырырга.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге Байлангар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, түбәндәгеләрдән тыш:
- 1 төркем инвалидлары;
- көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлар (курсантлар);
- 18 яшькә кадәрге баласын тәрбияләүче ялгыз аналар;
- 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан да күбрәк баласы булган аналар;
- 80 яшькә җиткәннәр һәм аннан да өлкәнрәкләр;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлар;

- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзалары, махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләр һәм аларның гаилә әгъзалары»

1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

**- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау** (су белән тәэмин итү челтәрләрен, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, материаллар сатып алу, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, су белән тәэмин итүне, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту буенча башка эш төрләре; су суырту манарасы сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, су суырту манарасы сатып алу һәм урнаштыру буенча башка эш төрләре);

**- янгынга каршы резервуарларны (янгын сулыкларын), янгын пирсларын урнаштыру, ремонтлау;** (янгын гидранты һәм комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру һәм карап тоту буенча башка эш төрләре)

**- торак пункт территориясен төзекләндерү** (Байлангар авылы территориясен төзекләндерү, проект-смета документлары, Байлангар авылы территориясен төзекләндерү буенча башка эш төрләре; Совет урамы тыкрыгын төзү, карап тоту һәм төзекләндерү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, Совет урамы тыкрыгын төзекләндерү буенча башка эш төрләре); (массакүләм ял итү урыннарын төзү, тоту, төзекләндерү, җиһазландыру һәм ремонтлау (парклар, спорт мәйданчыклары, мәдәни чаралар уздыру урыннары һәм башка массакүләм ял итү урыннары) һәм алар янәшәсендәге территорияләрне төзү, тоту, төзекләндерү, җиһазландыру һәм ремонтлау, инвентарь, җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, массакүләм ял итү урыннарын урнаштыру, карап тоту, төзекләндерү һәм җиһазландыру буенча башка эш төрләре);

**- традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү** (зират территориясен карап тоту һәм төзекләндерү, эш кораллары һәм инвентарь сатып алу, зират территориясен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре);

**- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау**(урам яктыртуны карап тоту, комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре);

- **торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту**(Байлангар авылында урам-юл челтәрен карап тоту, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, проект-смета документлары, юлларны карап тоту буенча башка эш төрләре); (юлларга вак таш һәм асфальт салу, ремонтлау һәм төзекләндерү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, юлларны төзү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре); (Байлангар авылында автомобиль күперен төзү һәм ремонтлау, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, башка эш төрләре);

- **җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү** (Байлангар авылы чишмәсен төзекләндерү, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, чишмә территориясен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре);

«РИЗА» - ? «КАРШЫ» - ?

5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүлү.

6. Байлангар авылы Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

7. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

8. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Җирлек башлыгы: И.Ф. Кәримуллин